СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

__________________ с. Сарманово №______________

20.06.2019 ел № 182

Сарман муниципаль районы Советының «Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 19 декабрендәге 103 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел 13 март 181 нче карары, Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Сарман муниципаль районы Советының «Авыл җирлегендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 19 декабрендәге 103 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11.1. пункт өстәргә:

"11.1. Субсидия-ташламалар бирү гражданның законлы көченә кергән суд акты белән расланган торак урыннарына һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча соңгы өч елдан да артмаган бурычлар булганда туктатыла.

Субсидия-ташламалар бирүне яңарту турында карар кабул иткәндә ул шулай ук субсидия-ташламалар бирү туктатылган айлар өчен дә түләнә.".

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO TATARSTAN .RU) һәм «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы "Сарман муниципаль районы"муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин